**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күәм авыл җирлеге Дусым торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“22” ноябрь 2024 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Дусым торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Дусым авылы территориясендә 2025 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Дусым торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

- Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм подстанция мәйданчыкларын, бүлү пунктларын, электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктырту өчен яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру, хезмәтләр өчен түләү);

- Коеларны төзекләндерү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (Дусым авылының Г.Кутуй урамындагы коены ремонтлау, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Дусым авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Күәм авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Дусым авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күәм авыл җирлеге башлыгы Хасбиуллин И.И.